**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**УЗЯКСКИЙ СЕЛЬСКИЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ**
**КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Хазиева ул., д. 8, п. Узяк, 422092
тел. (факс): (84360) 5-22-17,
E-mail: Uzk.Tul@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ҮЗӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Хәжиев ур., 8 нчы йорт, Үзәк бистәсе, 422092
тел. (факс): (84360) 5-22-17,
E-mail: Uzk.Tul@tatar.ru

ОКПО 93053615 ОГРН 1061675010165 ИНН/КПП 1619004370/161901001

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№54**

**КАРАР**
**«01» октября 2019 г.**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең 2019-2029 елларга транстпорт инфраструктурасын раслау турында**

Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2019 ел 26 июн 3 01-16/3255 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» гы 2015елның 25 декабрендәге 1440 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Үзәк авыл җирлегендә транспорт инфраструктурасын үстерүне куркынычсызлык дәрәҗәсен күтәрү белән тәэмин итү максатларында,

**К А Р А Р  Б И Р Ә М :**

1. 2019-2029 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Үзәк авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

В.Н.Котников

*Кушымта*

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән
РАСЛАНГАН
«01» октябрь 2019 ел №54

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҮЗӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ 2019 - 2029 НЧЫ ЕЛЛАРГА ТРАНСПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН КОМПЛЕКСЛЫ ҮСТЕРҮ ПРОГРАММАСЫ

п. Үзәк 2019 ел

# 1. ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Программаның исеме | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең 2019 - 2029 елларга транспорт инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программасы |
| 2 | Программаның заказ бирүчесе, эшләүчесе, башкаручысы | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 3 | Программаны эшләү өчен нигез | 2014 елның 29 нчы декабрендә кабул ителгән 456-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы федераль закон; 2015 елның 25 ноябрендә расланган №1440 номерлы «Җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программаларына карата таләпләрне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары; Татарстан Республикасы Президенты Р. Н.Миңнехановның «Муниципаль берәмлекләрнең транспорт инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программасын эшләү турында» 2016 елның 6 июнендәге 32661-ПР номерлы күрсәтмәсе. |
| 4 | Программаның максаты һәм бурычлары | Максат: Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегендә куркынычсызлык дәрәҗәсен күтәреп, транспорт инфраструктурасын үстерүне тәэмин итү.<br>Бурычлар: -транспорт инфраструктурасы объектларын төзүне, үзгәртеп коруны тәэмин итү;<br>-муниципаль берәмлек территориясендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру; |
| 5 | Транспорт инфраструктурасын үстерүнең максатчан | -җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәткечләре (Индикаторлары) | озынлыгы;<br>-транспорт инфраструктурасы объектларын төзү, реконструкцияләүгә проектлар саны;<br>-төзелгән, реконструкцияләнгән автомобиль юлларының озынлыгы;<br>- юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары саны. |
| 6 | Программаны тормышка ашыру срогы | 2019-2029 еллар. |
| 7 | Программаның чаралары | «Транспорт комплексы үсешенең өстенлекләре» дигән 5 бүлектә китерелгән |
| 8 | Финанслау чыганаклары | РТ бюджеты, МО бюджеты, бюджеттан тыш чыганаклар |
| 9 | Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре | муниципаль берәмлек территориясендә транспорт инфраструктурасын үстерү өчен шартлар тудыру; муниципаль берәмлек территориясендә юл хәрәкәте катнашучыларының иминлек дәрәҗәсен арттыру |

## 2.ГОМУМИ БЕЛЕШМӘЛӘР

Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге районның көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан, админстратив үзәк- Теләче авылы. Үзәк авыл җирлеге Теләче муниципаль районының Теләче, Иске Җөри, Алан, Шәтке, Айдар, Олы Нырсы, Олы Мәтәскә, Баландыш авыл җирлекләре, Питрәч муниципаль районының Янцар авыл җирлеге белән чиктәш.

Авыл җирлеге составына керә: 6 торак пункты: Үзәк бистәсе, Сауш авылы, Алга авылы, Петровский бистәсе, Шармаш авылы, Пановая Гора авылы. Авыл җирлегенең административ үзәге булып Үзәк бистәсе тора. Авыл җирлегенең административ үзәгеннән Теләче муниципаль районының административ әзгенә кадәр булган аралык 8 км тәшкил итә. Үзәк авыл җирлегенң 01.01.2019 елга халык саны 1779 кеше, Теләче муниципаль районының гомуми халык санынннан 13 % ны тәшкил итә.Авыл җирлегенң

территориясе - 126080000 кв.км.

| №<br>п/<br>п | Автомобиль юлы исеме | Озынлык, км | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | | | | | |
| | | | ц/б | а/б | Вак таш,чуер таш | жир | Шул исэптэн туры килмэгэннэр |
| 1 | Үзәк авыл җирлеге | **23,09** | **0,60** | **2,95** | **17,49** | **2,05** | |
| Алга авылы | | | | | | | |
| | Архипов урамы | 0,80 | | | 0,80 | | |
| | Мрясов урамы | 0,60 | | | 0,60 | | |
| | Кыр урамы | 0,90 | | | 0,90 | | |
| Пановая Гора авылы | | | | | | | |
| | Малов урамы | 0,85 | | | | 0,85 | |
| Петровский бистэсе | | | | | | | |
| | Державин урамы | 0,80 | | | 0,80 | | |
| Сауш авылы___ | | | | | | | |
| | Әнәс Кари урамы | 0,20 | | | | 0,2 | |
| | Баһавиева урамы | 0,70 | | | 0,7 | | |
| | Гарифуллин урамы | 1,20 | | | 1 | 0,2 | |
| | Сиражетдиновлар урамы | 1,70 | | 0,7 | 1 | | |
| | Тукай урамы | 0,90 | | | 0,9 | | |
| Үзәк бистэсе | | | | | | | |
| | Әүхәдиева урамы | 0,60 | 0,6 | | | | |
| | Галиев урамы | 0,72 | | | 0,72 | | |
| | Дударь урамы | 0,30 | | | 0,3 | | |
| | Кәримова урамы | 0,50 | | | 0,5 | | |
| | Ленин урамы | 1,50 | | | 1,5 | | |
| | Болын урамы | 0,20 | | | | 0,2 | |
| | Макаров урамы | 0,45 | | | 0,45 | | |
| | Яшьләр урамы | 1,00 | | | 1 | | |
| | Көньяк урамы | 0,35 | | | 0,35 | | |
| | Тукай урамы | 0,80 | | | 0,8 | | |
| | Татарстан урамы | 0,60 | | | 0,6 | | |
| | Хаҗиев урамы | 0,95 | | 0,95 | | | |
| | Хафизов урамы | 0,50 | | | 0,5 | | |
| | Шакиров урамы | 0,47 | | | 0,47 | | |
| Шармаш авылы | | | | | | | |
| | Бобровка урамы | 0,40 | | | 0,4 | | |
| | Заречная урамы | 1,20 | | | 0,8 | 0,4 | |
| | Киров урамы | 1,00 | | | 1 | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Тельман урамы | 1,20 | | 1,2 | | | |
| | Кече урам | 0,20 | | | | 0,2 | |
| | Мәктәп урамы | 1,50 | | 0,1 | 1,4 | | |

Үзәк авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең урам-юл челтәре озынлыгы буенча мәгълүмат

## 3.ТРАНСПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫНЫҢ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ.

Җирлек территориясендә тышкы транспорт бер төр - автомобиль транспортыннан гыйбарәт. Үзәк авыл җирлегенең торак пунктларында тышкы транспортның күләме зур түгел. Тышкы транспорт җирлекнең район һәм республика үзәкләре, күрше муниципаль берәмлекләр белән аралашуы ягыннан зур әһәмияткә ия.

Үзәк авыл җирлегенең территориясендә юл челтәрен үстерү өлешендә төп чаралар Теләче муниципаль районының Үзәк авыл җирлегенең 2020 елга кадәр социаль-икътисадый үсеш Стратегиясендә каралган.

Тышкы транспортны үстерү буенча Программа чаралары булып түбәндәгеләр тора:

1. Үзәк авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын норматив хәлгә (бөтен чор) китерү буенча чараларны территориаль планлаштыруда исәпкә алу.

2. Муниципаль берәмлек чикләрендә федераль һәм региональ әһәмияттәге автомобиль юлларын үстерү өчен җир кишәрлекләре бүлеп бирүдә ярдәм күрсәтү (бөтен чор).

3. Федераль һәм региональ әһәмияттәге автомобиль юллары полосаларыннан һәм сак зоналарыннан файдалану режимын саклауны тәэмин итү (бөтен чор).

### Җәмәгать транспорты.

Транспорт - һәркем файдалана алырлык, җитештерүчеләр һәм кулланучылар арасында продукциянең төрле төрләрен күчерә торган, икътисадның һәм халыкның йөк ташуга ихтыяҗларын канәгатьләндерә торган

җирлек инфраструктурасының мөһим состав өлеше. Транспортның тотрыклы һәм нәтиҗәле эшләве җирлекнең барлык предприятиеләрен йөк ташуга һәм уңышлы эшләүгә булган ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү өчен кирәкле шарт. Җирлектә пассажир транспортының төп һәм бердәнбер төре - такси һәм шәхси автотранспорт. Үзәк авыл җирлегенең территориясендә автотранспорт предприятиеләре юк. Җирлектә хәрәкәт итүләрнең күбесе шәхси автотранспортка һәм җәяүлеләр юлларына туры килә.

## 4. УРАМ-ЮЛ ЧЕЛТӘРЕ

Урам-юл челтәре торак пунктларның транспорт, инженер һәм социаль инфраструктурасының төп элементы булып тора. Авыл җирлегенең комплексы үсешендә юл челтәре һәм инфраструктура объектларының үсеше социаль әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып тора. Үзәк авыл җирлегенең урам-юл челтәре 23,09 км, шул исәптән каты өслеклесе – 21,04км. Җирлектә автомобиль юлларының күп өлешенә вак таш җәелгән.

Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең урам-юл челтәренең характеристикасы 1 нче Таблицада күрсәтелгән.

1 Таблица

| № п/п | Автомобиль юлының исеме | Озынлык, км | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | шул исәптән | | | |
| | | | ц/б | а/б | вак ташлы | җир |
| 1 | Алга авылы Архипов ур. | 0,80 | | | 0,8 | |
| 2 | Алга авылы Мрясов ур. | 0,60 | | | 0,6 | |
| 3 | Алга авылы Кыр ур. | 0,90 | | | 0,9 | |
| 4 | П.Гора авылы Малов ур. | 0,85 | | | | 0,85 |
| 5 | Петровский бистәсе Державин ур. | 0,80 | | | 0,80 | |
| 6 | Сауш авылы Әнәс Кари ур. | 0,20 | | | | 0,20 |
| 7 | Сауш авылы Баһавиева ур. | 0,70 | | | 0,7 | |
| 8 | Сауш авылы Гарифуллин ур. | 1,20 | | | 1 | 0,2 |
| 9 | Сауш авылы Сиражетдиновлар ур. | 1,70 | | 0,7 | 1 | |
| 10 | Сауш авылы Тукай ур. | 0,90 | | | 0,9 | |
| 11 | Үзәк бистәсе Әүхәдиева ур. | 0,60 | 0,6 | | | |
| 12 | Үзәк бистәсе Галиев ур. | 0,72 | | | 0,72 | |
| 13 | Үзәк бистәсе Дударь ур. | 0,30 | | | 0,3 | |
| 14 | Үзәк бистәсе Кәримова ур. | 0,50 | | | 0,5 | |
| 15 | Үзәк бистәсе Ленин ур. | 1,50 | | | 1,5 | |
| 16 | Үзәк бистәсе Болын ур. | 0,20 | | | | 0,2 |
| 17 | Үзәк бистәсе Макаров ур. | 0,45 | | | 0,45 | |
| 18 | Үзәк бистәсе Яшьләр ур. | 1,00 | | | 1 | |
| 19 | Үзәк бистәсе Көньяк ур. | 0,35 | | | 0,35 | |
| 20 | Үзәк бистәсе Тукай ур. | 0,80 | | | 0,8 | |
| 21 | Үзәк бистәсе Татарстан ур. | 0,60 | | | 0,6 | |
| 22 | Үзәк бистәсе Хаҗиев ур. | 0,95 | | 0,95 | | |
| 23 | Үзәк бистәсе Хафизов ур. | 0,50 | | | 0,5 | |
| 24 | Үзәк бистәсе Шакиров ур. | 0,47 | | | 0,47 | |
| 25 | Шармаш авылы Бобровка ур. | 0,40 | | | 0,4 | |
| 26 | Шармаш авылы Заречная ур. | 1,20 | | | 0,8 | 0,4 |
| 27 | Шармаш авылы Киров ур. | 1,00 | | | 1 | |
| 28 | Шармаш авылы Тельман ур. | 1,20 | | 1,2 | | |
| 29 | Шармаш авылы Кече ур. | 0,20 | | | | 0,2 |
| 30 | Шармаш авылы Мәктәп ур. | 1,50 | | 0,1 | 1,4 | |
| | **ИТОГО** | **23,09** | **0,60** | **2,95** | **17,49** | **2,05** |

## 5. ТРАНСПОРТ КОМПЛЕКСЫ ҮСЕШЕНЕҢ ӨСТЕНЛЕКЛӘРЕ

Муниципаль берәмлекнең транспорт комплексы үсешенең төп өстенлекләре булып, беренче чиратта, (2029 ел) торырга тиеш:

- гамәлдәге урам-юл челтәрен ремонтлау һәм реконструкцияләү.

Үзәк авыл җирлегенең территориясендә транспортны үстерү хакимиятнең төрле дәрәҗәләрендә: федераль, региональ, муниципаль бергәлекләрдә уртак тырышлыкка юнәлтелгән комплекслы якын килү нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш. Авыл җирлегенең транспорт системасын үстерүне планлаштырганда районның һәм тулаем регионның транспорт системасын перспективалы үстерүне исәпкә алырга кирәк. Авыл җирлегенең транспорт системасы регионның транспорт системасы элементы булып тора, шуңа күрә территориядә транспорт инфраструктурасын оптимальләштерүгә бәйле барлык бурычларны хәл итү бары тик җирле үзидарә органнары вәкаләтләре кысаларында гына хәл итела алмый. Транспорт инфраструктурасын үстерү буенча әлеге Программадагы мәсьәләләрне барлык дәрәҗәдәге бюджетлар катнашында гамәлгә ашыру күздә тотыла. Үзәк авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының бурычлары булып дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча оештыру чараларын һәм транспорт инфраструктурасын үстерү буенча инициативалы тәкъдимнәрне әзерләү тора. Транспорт инфраструктурасын үстерүнең төп юнәлешләре федераль дәрәҗәдә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 ел 22 ноябрь № 1734-р. номерлы күрсәтмәсе белән расланган Россия Федерациясе транспорт Стратегиясе белән билгеләнде. Транспорт Стратегиясе нигезендә транспорт системасын үстерүнең Стратегик максаты - икътисадның һәм җәмгыятьнең, конкуренциягә сәләтле сыйфатлы транспорт хезмәтләрендә, инновацион социаль юнәлешле үсеше ихтыяҗларын канәгатьләндерү.

Нәтиҗәле конкурентлыкка сәләтле транспорт системасын булдыру өчен 3 төп өлеш кирәк:

- конкурентлыкка сәләтле, югары сыйфатлы транспорт хезмәтләре;
- югары җитештерүчәнлекле имин транспорт инфраструктурасы һәм транспорт чаралары, алар конкуренциягә сәләтле югары сыйфатлы транспорт хезмәтләре белән тәэмин итәрлек дәрәҗәдә кирәк.;
- транспорт хезмәтләре тәкъдименең ихтыяҗын арттыру өчен шартлар

тудыру (югыйсә көндәшлек мохите булмаячак).

## 6. УРАМ-ЮЛ ЧЕЛТӘРЕН ОПТИМАЛЬЛӘШТЕРҮ

Үзәк авыл җирлегенең транспорт комплексы үсешенең билгеле бер өстенлекләре нигезендә, Программа тарафыннан урам-юл челтәрен оптимальләштерү буенча түбәндә китерелгән чаралар каралган.

Программада, нормативлар нигезендә, магистраль урам-юл челтәрен формалаштыру буенча тәкъдимнәр бирелә. Авыл торак пункты һәм авыл җирлеге чикләрендә урам челтәренең төп исәп-хисап параметрлары 42.13330.2011 СП «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» нигезендә кабул ителә.

Яңа торак төзелеше районнарында урамнарны һәм юлларны проектлаганда, урамнарның кызыл линияләрдәге проект киңлеген үтәргә кирәк, бу киләчәктә урамнарны киңәйтү максатыннан, җир кишәрлекләрен тартып алу һәм капиталь төзелеш объектларын сүтү буенча кыйммәтле чараларны тормышка ашырмаска мөмкинлек бирәчәк. Проектлана торган урамнар, норматив уклоннарны үтәү таләбе башкарылсын өчен, рельефта урнашырга тиеш. Катлаулы геоморфологик факторлар шартларында төп урамнарны проектлаштыру һәм төзүгә аерым игътибар бирергә кирәк.

## 7.МАШИНА КУЮ ҺӘМ ТРАНСПОРТНЫ ОЗАК ВАКЫТКА САКЛАУ УРЫННАРЫН ОЕШТЫРУ

Җирлек территориясендә автотранспортны саклау, нигездә, предприятие участоклары чикләрендә һәм җирлек халкының йорт яны участокларында, зур булмаган гараж кооперативларында башкарыла. Алга таба, халыкның автомобиль йөртү дәрәҗәсе артыр, дип фаразланыла торган күләмне исәпкә алып, җәмәгать билгеләнешендәге биналар янында автомобильләр кую урыннарын оештыруны күздә тотарга кирәк. Җиңел автомобильләрне даими һәм вакытлыча саклау йорт яны участоклары чикләрендә күздә тотыла.

Әлеге бүлек буенча башкарылырга тиешле чаралар:

1. Җәмәгать билгеләнешендәге биналарның проект сыйдырышлылыгы нигезендә, аларны төзү өчен бирелә торган участокларда тиешле санда парковка урыннарын урнаштыруны административ чаралар белән тәэмин итү (бөтен чор);

2. Хезмәт күрсәтү объектлары янында машина кую урыннары төзү (бөтен чор);

3. Иң зур җәлеп итү урыннарында җәмәгать тукталышлары урыннарын оештыру (беренче чират-хисап срогы).

## 8 ҖӘЯҮЛЕЛӘР УРАМНАРЫ ҺӘМ ВЕЛОСИПЕД ЮЛЛАРЫ СИСТЕМАСЫН БУЛДЫРУ: МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ ЧИКЛӘНГӘН ЗАТЛАР ӨЧЕН КИРТӘЛӘРСЕЗ МОХИТ БУЛДЫРУ.

Экологик чиста мохитне саклау йөзеннән, корреспонденция өчен зур булмаган кисемтәләр булганда, торак пунктлар территориясендә Программада җәяүлеләр өчен урамнар системасы каралган. Җирлек Программасы буенча халыкның аз хәрәкәтле төркемнәре өчен киртәләрсез мохит булдыру каралган. Әлеге максат белән, иҗтимагый биналарны проектлаштырганда, норматив тайпылышлы пандуслар урнаштыру, тротуарларны каплауны камилләштерү һәм башкалар буенча кирәкле барлык таләпләр куелырга тиеш.

Әлеге бүлек буенча чаралар:

1. Җәяүлеләр күбрәк булган урамнар системасын формалаштыру (исәп-хисап вакыты- перспектива);

2. Киртәләрсез мохит тудыручы төзүчеләрне башкаруның административ чаралары белән тәэмин итү (бөтен чор)

## ПРОГРАММАНЫҢ ЧАРАЛАРЫ

| Чара исеме | Объектның урнашу урыны | Тормышка ашыру срогы |
|---|---|---|
| Җирле әһәмияттәге | Үзәк бистәсе _____ | 2019-2029 еллар. |

| | | |
|---|---|---|
| автомобиль юлларының техник документларындагы белешмәләрне актуальләштерү, бүлеп бирелгән полосаларны билгеләү | | |
| Автомобиль юлларындагы һәм җирлек урамнарындагы барлык инженерлык корылмаларының техник торышын бәяләү белән инвентаризацияләү | Үзәк бистәсе | 2019-2029 еллар |
| Юллар өслеген үзгәртүне исәпкә алып, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының расланган исемлегенә үзгәрешләр кертү | Үзәк бистәсе | 2019-2029еллар |
| Территорияләрне планлаштыру документациясен эшләп чыгару белән комплекста хәл ителә торган юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча чаралар комплексын эшләү һәм тормышка ашыру | Үзәк бистәсе | 2019-2029еллар |
| Торак пунктларның урамнарын реконструкцияләү, төзекләндерү, каты өслек урнаштыру | Үзәк бистәсе | 2019-2029еллар |